"РАСЛЫЙМ"

_________________ Г.И.Сабирова
"Ватаным Татарстан" газетасының
баш мөхәррире

# КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ЮГАРЫ ЖУРНАЛИСТИКАҺӘМ МЕДИАКОММУНИКАЦИЯЛӘР МӘКТӘБЕНӘ "ЖУРНАЛИСТИКА" ЮНӘЛЕШЕНДӘ "ЯҢА МИЛЛИ МЕДИА ЧАРАЛАРЫ" ПРОФИЛЕ БУЕНЧА (БАКАЛАВРИАТ) УКЫРГА КЕРҮ ӨЧЕН "ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН" ГАЗЕТАСЫНЫҢ ИҖАДИ БӘЙГЕ НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## 1. БӘЙГЕНЕҢ МАКСАТЫ ҺӘМ ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ

1.1. "Ватаным Татарстан" газетасында эшләү өчен милли кадрлар әзерләү;

1.2. Татар мәктәпләрен тәмамлаган, татар телен камил белгән, талантлы балаларга журналист һөнәрен алырга ярдәм итү;

1.3. "2014-2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү" дәүләт программасын гамәлгә ашыруда катнашу;

1.4. Бәйгене "Ватаным Татарстан" газетасы дәүләт бюджет учреждениесы уздыра.

## 2. ГОМУМИ ТӘРТИПЛӘР

2.1. Бәйгедә, кайда яшәвенә карамастан, Россия гражданы булган, татар телен камил белгән, гомуми урта белем бирү мәктәпләре һәм махсус урта белем бирү учреждениеләренең чыгарылыш сыйныф укучылары катнаша ала.

2.2. Катнашучының иҗади мәкаләләр яза белүе шарт.

2.3. Катнашучының рус теле һәм әдәбияты фәннәреннән Бердәм дәүләт имтиханын тапшыруы шарт.

2.4. Катнашучының иҗади портфолиосы (төрле матубгат чараларында басылып чыккан язмалары тупланмасы) һәм уңыш портфолиосы (төрле бәйгеләрдә, фән олимпиадаларында катнашу, җиңү) булу хуплана.

## 3. БӘЙГЕНЕ УЗДЫРУ УРЫНЫ ҺӘМ ВАКЫТЫ

3.1. Укырга керү өчен иҗади бәйге 2019 елның 1 маеннан 30 июненә кадәр 2 турда уздырыла.

3.2. I тур - читтән торып уздырыла.

3.2.1. Анда катнашу өчен редакциягә социаль-иҗтимагый темага, проблема күтәрелгән язма җибәрергә кирәк. Күләме 14 нче шрифт, 1,5 интервал белән 3 биттән артмаска тиеш.

*Язмага таләпләр:* проблема күтәрелү, үз фикереңне җиткерә алу, фикер яңалыгы, стилистик камиллек.

3.2.2. Шулай ук катнашучыдан үзе турында 1 минутлык видеорлик төшереп җибәрүе сорала (смартфон камерасына төшерергә дә ярый).

*Видематериалга таләпләр:* 1 минуттан артмау, үзең турында үзенчәлекле итеп сөйләү

3.2.3. Язманың да, видеоматериалның да татар телендә булуы шарт.

3.3 Материалларны 2019 елның 25 маена кадәр konkurs_vt@mail.ru адресына җибәрү яки Казан, Академия урамы, 2 йорт адресы буенча редакциягә китереп бирү шарт.

3.4. II тур - беренче турдан узучылар редакциягә әңгәмәгә һәм өстәмә иҗади биремнәр үтәргә чакырыла. Ул Казан, Академия урамы, 2 йорт адресы буенча уздырылачак. Вакыты турында, I тур тәмамлангач, өстәмә хәбәр ителәчәк.

## 4. БӘЙГЕНЕҢ БАШКА ШАРТЛАРЫ

4.1. Бәйге нәтиҗәсе буенча 1 җиңүче ачыкланачак һәм ул Казан федераль университетының Югары журналистика һәм медиакоммуникацияләр мәктәбендә "Милли һәм глобаль медиа" юнәлеше буенча (бакалавриат) бушлай белем алачак.

4.2. Уку дәверендә җиңүче "Ватаным Татарстан" газетасында иҗади практика узарга һәм укып бетергәч 3 ел эшләргә тиеш.

4.3. Бәйгедә катнашу катнашучының аны уздыру тәртибе белән таныш булуын, шуңа ризалыгын күрсәтә. Таләпләр һәр катнашучы өчен үзгәрешсез кала.

4.4. Һәр катнашучы редакциягә үзе турында шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалык кәгазе бирергә тиеш (нигезләмәгә 1 йөкләмә).

4.5. Бәйгедә катнашу катнашучының үзе турындагы шәхси мәгълүматны бәйге барышында һәм ул тәмамланганнан соң мәгълүмати максатларда кулланырга; массакүләм мәгълүмат чараларына бәйге турында бушлай интервью бирергә ризалыгын аңлата.

## 5. БӘЙГЕГӘ НӘТИҖӘ ЧЫГАРУ

5.1. Бәйгегә килгән эшләрне һәм бәйге барышында редакциягә килеп үтәлгән биремнәрне жюри бәяләячәк. Аның составы:

1. Сабирова Гөлнара Ильяс кызы - "Ватаным Татарстан" газетасының баш мөхәррире - жюри рәисе.

2. Гарифуллин Васил Заһит улы - КФУның Югары журналистика һәм массакүләм коммуникацияләр мәктәбенең Милли һәм глобаль медиа кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы, профессор.

3. Хөснуллин Илнар Хәлил улы - "Ватаным Татарстан" газетасының баш мөхәррир урынбасары.

4. Гыймадова Гөлинә Шәйхлислам кызы - "Ватаным Татарстан" газетасының бүлек мөхәррире